Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Пестречинского
муниципального района
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль
районы
башкарма комитеты
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» март, 2026 ел № 132-п

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрын раслау турында» Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 30 октябрендәге 845 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2025 елның 5 мартындагы 119-п номерлы үзгәрешләре белән редакциядә)

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм аларның реестрын алып бару урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары нигезендә Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрын раслау турында» Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 30 октябрендәге 845 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы (2025 елның 5 мартындагы 119-п номерлы үзгәрешләре белән редакциядә) карарга үәгәрешләр кертергә.

2. Каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрын яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

И.Р. Дәүләтханов